ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.04.2019 Олы Кайбыч авылы № 173

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 нче елның 30 нчы апрелендәге 222 номерлы “Мәктәпкәчә белем бирү төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм теркәү” муниципаль хезмәте күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2018нче елның 26 декабрендәге 1975/18 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015нче елның 10нчы мартында расланган 1389/15 номерлы “Мәктәпкәчә белем бирү төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм теркәү” муниципаль хезмәте күрсәтү Административ регламентының якынча формасына үзгәрешләр кертү турында” боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 нче елның 30 нчы апрелендәге 222 номерлы “Мәктәпкәчә белем бирү төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм теркәү турында ” карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтү “Мәктәпкәчә белем бирү төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм теркәү” Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктка:

«Уку елы чорында каралган тәртиптә буш урыннар барлыкка килсә, Административ регламентның 3 пунктында билгеләнгән тәртиптә Оешманы комплектка тутыру тормышка ашырыла»;

3.4.6 подпунктның 4нче абзацын төшереп калдырырга;

3.4.6 подпунктның 6 абзацында «5 эш көненнән дә артык түгел» сүзләрен «1 эш көненнән дә артык түгел» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.2 подпунктның 3 абзацында «3 ай эчендә» сүзләрен «1 ай эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.4 подпунктның 1нче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Көтелгән кабул итү датасы Гариза бирүче юлламаны кире кагу турында мөрәҗәгать иткән көннән дә алдарак булмаган датага алмаштырыла»;

3.5.5 подпунктның 1нче абзацында «Оешма җитәкчесе Системада гаризага “Килмәде” статусы бирә” сүзләрен «Гаризага Системада “Килмәде” статусы бирелә” сүзләренә алмаштырырга;

3.5.6 подпунктның 1нче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Раслау вакытында кабул итүнең көтелгән датасы Гариза бирүче муниципаль хезмәткә мохтаҗ булуын раслап мөрәҗәгать иткән көннән дә алдарак булмаган датага алмаштырыла»;

3.6.2. подпунктның 1нче абзацында «3 ай эчендә» сүзләрен «1ай эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.6.3 подпунктның 1нче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

«Раслау вакытында кабул итүнең көтелгән датасы Гариза бирүче муниципаль хезмәткә мохтаҗ булуын раслап мөрәҗәгать иткән көннән дә алдарак булмаган датага алмаштырыла».

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәгариф бүлеге» МКУнә:

2.1. Әлеге карарны муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә җиткерергә;

2.2. “Мәктәпкәчә белем бирү төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм теркәү” муниципаль хезмәтен кулланучыларга барып җитүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ш. Бикбовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров